| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 апрель г.Казань № 427

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 25 май, 394 нче; 2020 ел, 17 апрель, 297 нче; 2020 ел, 23 ноябрь, 1050 нче; 2021 ел, 20 март, 152 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне

планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «җирлекнең, шәһәр округының генераль планы проектын,» сүзләреннән соң «, җирлекнең, шәһәр округының расланган генераль планына кертелә торган үзгәрешләрне» сүзләрен өстәргә, «ике айдан» сүзләрен «30 календарь көннән» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның беренче абзацында «җирлекнең, шәһәр округының расланган генераль планына кертелә торган үзгәрешләрне (алга таба – расланган территориаль планлаштыру документлары)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Россия Федерациясенең ике һәм аннан күбрәк субъектларын территориаль планлаштыруның расланган схемаларын, Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган Россия Федерациясе субъектларын территориаль планлаштыру схемаларын, муниципаль районны территориаль планлаштыру схемаларын Россия Федерациясен территориаль планлаштыруның расланган документларына, Россия Федерациясенең ике һәм аннан күбрәк субъектларын территориаль планлаштыруның расланган документларына, Татарстан Республикасын территориаль планлаштыруның расланган схемасына туры китерү өлешендә үзгәрешләр керткәндә.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Бу Тәртипнең 3.1 пунктында каралмаган очракларда, Россия Федерациясенең ике һәм аннан күбрәк субъектларын территориаль планлаштыруның расланган схемасына, Россия Федерациясе субъектын территориаль планлаштыруның расланган схемасына, муниципаль районны территориаль планлаштыруның расланган схемасына кертелә торган үзгәрешләрне карау срогы документ проектыннан файдалана алуны тәэмин итү турында хәбәрнамә кергән көннән ике календарь айдан арта алмый.»;

9 пунктта «җирлекнең, шәһәр округының генераль планы проектын,» сүзләреннән соң «, җирлекнең, шәһәр округының расланган генераль планына кертелә торган үзгәрешләрне» сүзләрен өстәргә, «20 календарь көн» сүзләрен «10 календарь көн» сүзләренә алмаштырырга;

9.1 пунктта «җирлекләрнең, шәһәр округларының расланган генераль планнарына» сүзләрен төшереп калдырырга, «җиде календарь көннән» сүзләрен «10 календарь көннән» сүзләренә алмаштырырга;

9.2 пунктта «җирлекләрнең, шәһәр округларының расланган генераль планнарына» сүзләрен төшереп калдырырга;

11 пунктта «биш календарь көн» сүзләрен «өч календарь көн» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Министрлыкка бер генә килештерүче органнан территориаль планлаштыру документы проекты белән килешмәү турында бәяләмә кергәндә, Министрлык бу Тәртипнең 9, 9.1 һәм 9.2 пунктларында билгеләнгән сроклар чыккан датадан җиде эш көне эчендә территориаль планлаштыру документы проекты белән килешмәү турында бәяләмә әзерләү өчен нигез булган искәрмәләрне җайга салу максатларында килештерү киңәшмәсен үткәрә.»;

18 пунктта «биш календарь көн» сүзләрен «өч календарь көн» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин